## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“27” март 2026 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 20.03.2025 ел №33-ФЗ Федераль законның 45, 69 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2026 елның 27 мартында 9 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча:

Татарстан Республикасы Әтнә Муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл жирлегенең Иске Мәңгәр торак пунктында гражданнар җыенынын 18.11.2025 ел № 2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру) эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).”;
- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сулыгын урнаштыру) эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).»;

Карарның 3 пунктында «2024» саннарын «2025»саннарына алмаштырырга.».

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **163** (йөз алтмыш өч) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 82(сиксән ике) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
“Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 82 (сиксән ике) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның **0** (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Иске Мәңгәр авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Иске Мәңгәр торак пунктында Гражданнар Җыенының 18.11.2025 ел, № 2 карарына үзгәрешләр кертү:

“2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү

яктырткычларны, чыбыкларны ремонтлау өчен материаллар сатып алу, лампаларны алыштыру) эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).";

- Янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын сулыгын урнаштыру) эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).»;

Карарның 3 пунктында «2024» саннарын «2025»саннарына алмаштырырга.».

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлегенең Иске Мәңгәр авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында: http://atnya.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы Филатова Ф.Ф.